КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 4 февраль г.Казань № 56

Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыру чараларын тормышка ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Бу락карарга теркәлгән Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар ризык белән тукланулуын оештыру чараларын тормышка ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль районнары

һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 4 февраль, 56 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыру чараларын тормышка ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында муниципаль районнар һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыру чараларын тормышка ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү һәм бүлү тәртибен билгели.

2. Бу Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Субсидияләр бу Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидияләр бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерийлары – муниципаль берәмлек территориясендә башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануы оештырылган муниципаль гомуми белем бирү оешмалары булу.

5. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында субсидияләрне бүлү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон белән раслана.

Субсидияләрне финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе субъектларының Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында, муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның бушлай кайнар туклануын оештыру чараларын гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт

программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге1642 номерлы карары, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында төзелгән күрсәтелгән субсидияләр бирү турында килешү нигезендә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетына кергән акчалар була.

6. Субсидияләр бирү шартлары түбәндәгеләр була:

муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыруга карата санитар-гигиеник таләпләр һәм укучыларның туклануын оештыруга карата Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеге яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе белән расланган норматив хокукый актларда билгеләнгән башка таләпләр нигезендә укучыларның кайнар ризык балән туклануын оештыру өчен шартлар булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) финанслашу максатларында субсидия бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре аларны үтәү өчен җитәрлек күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган субсидия күләмен кертеп) булу;

муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан расланган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыру чараларының әлеге белем бирү оешмаларында укучылар санының 100 процентын колачлауны тәэмин итә торган исемлеге булу;

муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча йөкләмәсен күздә тота торган Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү һәм Килешү белән каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

7. Субсидияләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү турында» 2014 елның 30 сентябрендәге 999 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү тәртибе нигезендә төзелә торган Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы арасындагы, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган түрнәк форма буенча төзелгән Килешү нигезендә бирелә.

8. I-муниципаль берәмлек бюджетына субсидия күләме ($S_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = Ч_{детодней_i} \times N_{туклану} \times Z_{финанслашу},$$

монда:

$Ч_{детодней_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучылар өчен бу Кагыйдәләрнең 9 нчы пункты нигезендә исәпләп чыгарыла торган балалар көне саны;

$N_{туклану}$ – башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча бер укучыга кайнар ризыкның ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана торган 1 көнгә уртача кыйммәте;

$Z_{финанслашу}$ - i-муниципаль берәмлекнең Татарстан Республикасы бюджетыннан чыгым йөкләмәләрен финанслауның Татарстан Республикасы өчен күрсәтелгән чыгым йөкләмәсен өстәмә финанслауның иң чик дәрәҗәсенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең расланган күрсәтмәсе белән тигез дәрәҗәдә иң чик дәрәҗәсе, процент.

9. I-муниципаль берәмлегендә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучылар өчен балалар көне саны ($Ч_{детодней_i}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Ч_{детодней_i} = Ч_{детей\ 1\ кл_i} \times Дней_{1\ кл} + Ч_{детей\ 2-4\ кл_i} \times Дней_{2-4\ кл},$$

монда:

$Ч_{детей\ 1\ кл_i}$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнварына федераль статистик күзәтү мәгълүматлары буенча i-муниципаль берәмлегендә 1 нче сыйныфта укучылар саны;

$Дней_{1\ кл}$ – 1 нче сыйныф укучылары өчен 165 көнгә тигез булган уку көннәре;

$Ч_{детей\ 2-4\ кл_i}$ – агымдагы финанс елының 1 гыйнварына федераль статистик күзәтү мәгълүматлары буенча i-муниципаль берәмлегендә 2 - 4 сыйныфларда укучылар саны;

$Дней_{2-4\ кл}$ – 2 - 4 нче сыйныфлар укучылары өчен 165 көнгә тигез булган уку көннәре;

10. Муниципаль берәмлек бюджетының субсидияләр исәбеннән финанслаша торган чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме, Килешүдә билгеләнгән субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү зарурлыгыннан чыгып, муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар белән раслана (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлеге белән билгеләнә).

11. Субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткече булып муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын 100 процент колачлау тора.

12. Муниципаль берәмлекләр тарафыннан субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү Килешүдә билгеләнгән һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы, түләүсез кайнар ризык белән тукланучы укучыларның өлеше – субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренең фактагы ирешелгән мәгънәләрен чагыштыру нигезендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары Министрлыкка Килешүдә каралган форма, вакытлар һәм тәртип буенча финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган муниципаль берәмлекләр бюджетлары чыгымнары

һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре мәгънәләре турында хисаплар тапшыра.

14. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидияләрнең максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

15. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына субсидия күчерү Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына гамәлгә ашырыла.

16. Килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта Татарстан Республикасы бюджетына муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне кире кайтару тәртибе һәм шартлары һәм аннан соң алардан файдалану Килешүдә һәм бюджет законнарында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

17. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидия бирү шартлары бозылган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

18. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидияләр бирү шартлары үтәлешен тикшерүдә тоту Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

19. Субсидиядән максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

20. Агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган субсидия акчасы агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидияләрнең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемενә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

---